Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 30 апреле 52№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 27 сентябрендәге «Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын ( иҗтимагый фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 189 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 30 декабрендәге «Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 494-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12 статьяның 3 абзацында «муниципаль берәмлек» сүзләреннән соң «, әлеге Тәртипнең 3.1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш.» сүзләрен өстәргә.

Түбәндәге эчтәлекле 3.1 абзац белән тулыландырырга;

«3.1. Җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, шәһәр округының генераль планы территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлаулары территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,<br>Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин